Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Кляшевская начальная общеобразовательная школа – детский сад»
Тетюшского муниципального района РТ

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 157D1A83037354A4EFFA6819895906F2
Владелец: БУРГАНОВА САНИЯ ИБРАГИМОВНА
Действителен с 07.04.2023 до 30.06.2024

«Утверждаю»
Директор _____________/С.И.Бурганова/
от «____»________________2023 г.

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА**
учебного предмета **«Литературное чтение на родном (татарском) языке»** 4 класс

Хамидуллина Гульшат Ахметовна,
учитель начальных классов
первой квалификационной категории

Принято на заседании
педагогического совета
протокол №1
от «      » августа 2023 года

2023 год

**Аңлатма язуы**

1. 05.03.2004 елда РФ Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган башлангыч белем бирү дәүләт стандарты Федераль компонентына (Приказ №1089);
2. Дәүләт стандартының Федераль компонентына нигезләнгән башлангыч мәктәпләрнең татар теле фәненнән үрнәк программасына Казан 2011
3. 29.08.2011 елда ТР Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган гомумбелем бирү учреждениеләре өчен региональ базис укыту планына(Приказ №9282/11);
4. 06.10.2009 нчы елда РФ Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан расланган “Гомуми башлангыч белем бирү федераль дәүләт стандартын гамәлгә кертү” турындагы боерыгына (Приказ №373);
5. РФ һәм ТР “Мәгариф турындагы Закон” ына;
6. Белем бирү учреждениеләрендә укыту процессында куллану өчен рөхсәт ителгән “Перспективалы башлангыч мәктәп” концепциясе һәмбелем бирүнең яңа стандартлары таләпләренә туры килгән һәм рөхсәт ителгән региональ дәреслекләр исемлегенә;

7 Белем бирү оешмасының гомуми башлангыч белем бирү буенча икенче буын гомуми белем бирү

8. Г.М.Сафиуллина,М.Я.Гарифуллина, Ф.Ф.Хәсәнова, Ә.Г.Мөхәммәтҗанова, “Әдәби уку”( Казан, “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2014 нче ел) дәреслекләренә нигезләнеп төзелде.

Әдәби уку фәненнән эш программасы “Перспективалы башлангыч мәктәп” концепциясе һәм икенче буын гомуми белем бирү федераль дәүләт стандартлары таләпләренә туры килә. Программа яңа укыту стандартлары таләпләрен искә алып, үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспективалы башлангыч мәктәп» концепциясенә нигезләнеп эшләнгән.

**ӘДӘБИ УКУ ДӘРЕСЛӘРЕ ПРОГРАММАСЫ** **4 сыйныф** **(34 СӘГАТЬ)**

**Халык авыз иҗаты.**
**Мифлар турында гомуми күзаллау булдыру.**
Борынгы халыкларның тормышы, кеше һәм табигать арасындагы мөнәсәбәт. Тормыш агачы. Тотем хайван һәм үсемлекләр,кешеләрнең аларга карашы, борынгы традицияләрнең сакланышы.
**Тылсымлы әкиятләр.**
Дөнья турында борынгы күзаллаулар чагылышы. Тылсымлы әкият герое. Тылсым дөньясы. Тылсымлы предметлар, сихри саннар, сүзләр, тылсымлы булышчылар, тылсымлы әкият законнары: әкият герое өеннән чыгып китә. Максатка ирешү юлы (тылсым дөньясы, карурманнар аша үтүче юл, сынаулар, тылсымлы булышчы ярдәме, җиңү шатлыгы.) Халык әкиятләренең мифлар, легендаларда чагылышы.
**Риваять һәм легендалар.**
Риваять һәм легендаларда сөйләнгән геройлар, аларның кичерешләре. Тарихи бәйләнеш. Төрле атамалар. Аларның килепчыгышы.Риваять һәм легендаларда бирелгән вакыйгаларның әкиятләрдә чагылышы.
**Автор әкиятләре.**
Автор әкиятләренең халык әкиятлре белән охшашлыгы (жанр һәм сюжет). Халык әкиятлрендәге тылсым юлы белән җиңүләр, авторәкиятләрендә акыл белән эш итеп уңышка ирешү, ярату һәм яратыла белүнең көче.
**Фольклор жанрының тормышта, хәзерге вакытта яшәеше.**
Халык традицияләре һәм бәйрәмнәре. Символик төшенчәләр. Гимннар (Татарстан гимны). Халык һәм автор әкиятләре.
**Хикәя.**
Хикәя жанры турнда күзаллау формалаштыруны дәвам итү. Хикәя геройлары, аларның портреты һәм характер үзенчәлекләренең башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырмача характеристика. Герой яшәгән тирәлек,пейзаж.Хикәядәге чынбарлык чагылышы. Әдәби тел берәмлекләре.
**Әкият һәм хикәя жанрының үзгәлеге турында күзаллау формалаштыру.**
Әкият һәм хикәя жанрларының композиция үзенчәлеген (күзәтүләр аша) аңлату. Укучы-тыңлауга табигый көчләрнең серен, әкиятгеройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройлары-ның характерларында тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү.
**Шигърият.** Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөнья матурлыгын шагыйрьөчен илһам чишмәсе булуын инандыру. Шагыйрьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет.
Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру,контраст,җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлысөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре:темп,тавыш көче,тон,сөйләм мелодикасы(тавышны күтәрү ,түбәнәйтү).
**Әсәр авторлары турында.**
Шагыйрь, язучы, рәссамның биографиясе.

а) әсәрдә авторлар кичереше;
ә) автор күзәтүләренең чагылыш;
б) хәзерге заман авторлары белән очрашу, балаларның авторга сораулары, җаваплар.

**Библиографик культура формалаштыру.**

Эчтәлек бите белән танышу, аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү, кече яштәге мәктәп баласының дәреслектән тыш эчтәлгеноештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү. Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп өч элементын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру. Төрлеҗыентыклар төзергә өйрәнү.

**Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру.**

Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру *( интонация, тон, темп саклап кычкырып уку)*. Автор бирергә теләгән картинаны күзал-лау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда, үз урыныңны белеп, чират буенча уку. Укылган әсәргә анализ ясау. Уку техникасын үстерү.

**4 нче сыйныфта укыла торган әсәрләр**

**Халык авыз иҗаты.**

**“Җир ничек яралган?”** (легенда), “**Күкнең күтәрелүе** (хикәят), **“Айдархан һәм сәхабәләр**, (легенда), “**Пәйгамбәрнең тууы һәм аныңбалачагы”, “Абага чәчәге (**хикәят), “**Ак бүре**”(риваять), **“Кырык кыз**”( риваять), “**Мәрҗан каласы һәм унике кыз”** (хикәят), “**Дөньяратылу турында**” (миф), **“Хапи алла турында”** (миф), “**Чыршы ни өчен мәңге яшел?”** (легенда) . әкиятләр: **“Ак байтал”, “Ак бүре”, “Еланнар патшасы Шаһмара”, “Үги кыз” , “Ике кыз”, “Бумеранг”**(Австралия халкы әкияте).

**Борынгы язучылар һәм татар әдәбияты классикларыКол Гали**

“Кыйссаи Йосыф”.

**Г. Тукай :** “Таз”, “Яз галәмәтләре”.

**Дәрдемәнд:** “Гали”.

**З. Ярмәки: “**Иртә”, “Ак каен”.

**М.Җәлил:** “Дару”.

**К.Насыйри.** “Каз итен коймакка төреп, каймакка манып ашау”.

**Н.Исәнбәт:** “ Кышкы төндә”, “Туган ил”, “Өч матур сүз”.

**Ш.Бабич:** “ Тын төн”, “Габдулла әфәнде Тукай”. .

**А. Алиш**. “Сертотмас Үрдәк”.

**Г.Кутуй**.” Яшен”.

**Ш.Галиев**:”Кол Галигә”, “Алсу дөнья”, “Җирдә миңа ни кирәк?”, “Урман ява”, “Тукран сые”.

**Г.Ибраһимов:** “ Укудан кайткач”.

**Г.Галиев**.” Бибкәй аланы”.

**Ф.Әмирхан**. “ Кечкенә хезмәтче”. К.Нәҗми:
“Нәсимәнең беренче эш көне”.**З.Бәшири**: “ Бер
асрауның аһ-зары”.
**Н.Думави**: “ “Беренче кар”, “Ятим бала”.
**М.Мәһдиев**: “Бәхилләшү”.
**С.Хәким**: “ “Яратам мин”, “Тегермән стенасындагы язулар”.
**Ә.Фәйзи** :”Асрарга бала бирәм”.
**Ф.Хөсни**:”Малай белән солдат”.
**Ш.Рәкыйпов**: “ Төнге очыш”.
**И.Туктар:** “Букет”, “Бер каен үсә”.
**Г.Хәсәнов:** “ Аккош”, “Абага”.
**Г.Сабитов:** “Кадерле ул туган як!”, “Чәчәк нигә боекты?”.
**Н.Арсланов:** “Халкыма”.
**Җ.Тәрҗеманов**: “Шуктуган”, “Тукран малае Шуктуган”.
**Л.Ихсанова** : “ Шомырт чәчәкләре ак кына”.
**Ф.Яруллин**: “Буар елан”.
**М.Әгъләмов:** “Матурлык минем белән”.
**Зөлфәт:** “Кыз тавы”. **С.Шакир: “**
Ландыш чәчәге”.**Р.Хафизова:**
“Кирлемән”.
**Г.Латыйп:** “Минем нәсел”.
**Р.Гыйззәтуллин:** “Язгы моң”.
**К.Тимбикова:** “Бану әби сабагы”.
**К.Сибгатуллин:** “Чыпчык”, “Бөтен кеше бүген шундый әйбәт”.
**Роб.Әхмәтҗанов:** “Безнең шигырь”.
**Р.Хисмәтуллин:** “Аһ. Бер китсә кирегә...”

**Рус язучылары:**
Л. Толстой6 “Слива төше”.
Н. Сладков: “Тыштан ялтырый. ‘хn&у калтырый».

**Татар язучылары һәм шагыйрьләре (бүгенге көн язучылары)**
Р. Миңнуллин: “Иртән иртүк”, “Атказанган сандугач”, “Машина тавышлы көчек турында кечкенә әкият”, “Сабантуйда”, “Татарларым”,“Минем телем”, “Утыз Имәнине укыганда туган уйлар”.
Р. Фәйзуллин: “Быелгы яз”, “Минем әти”.

Х.Камалов: “ Археолог”.
Ә.Рәшит: “ Нәсел агачы”.
К.Булатова:”Кичә генә”, “Шушы яктан, шушы туфрактан без”.
Ж.Дәрзаман: “Бөҗәкләр белән сөйләшү”.
Р. Вәлиева: “Изгеләр тавы”, Энҗе чәчәк”. “Бөтен дөнья ак кына”, “Онытма!”.
Р. Вәлиев: “Кошлар кайта”, “Кайтчы, Сөембикә”, “Эт кояшы” (өзек), “Ватаным”.Н.
Әхмәдиев: “Хәерле иртә”.
И.Гыйлаҗев: “Тутыкмас тотка”, “Охшашлык”.
Р.Харис: “Татарстан әләме”, “Зөләйха”, Ак карлар арасында”, “Елмай”, “Туган җирем”, “Фронтовиклар”.Л.
Лерон: “Кыхмырый, Мыхмырый һәм Шыхмырый”.
Э. Шәрифуллинаб “ Табигатьнең бер бөртеге”, Без татар балалары”, “Тормыш яме”.
Г. Гыйльманов: “ Чишмәгә бардык”, Кайтаваз”, “Курай”, “Җавапсыз легенда”, “Минем исемем – Бүрек”.В.
Нуриев: “Ачуланма инде. Илһам!”
Г. Рәхим:”Көз йөри”,  “Көзге моң”, “Көзге урман”, “Песнәк”, “Апрель”.Р.
Корбан:  “Көз нинә моңлы?”, “Ярдәм итик”, “Курай”.
Йолдыз: “ Очрашу”.
Р.Мингалим: “ Бүген төнлә күккә кара”.
Батулла: “ Су иязләре”(әкият), “Терек-терек кырмыска”, “Салават күпере кайда йоклый?”
В.Хәйруллина “ Хәерле көн”, “Алмаштыру”,“Наз”, “Чикерткә”.
М.Мирза: “ Көз”, “Балачак хатирәсе”.
Ф.Бәйрәмова: “Кара пулат”.
Мөҗәһит: “Бер яфрак зары”.
Д.Гайнетдинова: “Исәнме, яңа көн”, “Батыр Хәбир”.
Л.Гыймадиева: “Кара урман, караңгы төн”.
Н.Сәйяр: “ Айсылу”. Р.Рахман: “
Кесәл”. Н.Каштан: “ Әрем исе”.
Г.Вәлиева: “Кызыктырсалар да”, “Карт алаша колагы”. Ф.Тарханова:
“Без бәлеш пешерәбез”, “Килде пилмән ашыйсы”.И Нәбиуллина: “Тәмле
тел”.
Ф. Мәҗитов: “Яңгыр кызы Гөлтамчы”.
Г.Мөхәммәтшин: “ Туган як”.
М.Галиев: “ Туган як”.
Г.Морат: “ Чит тел”.
С.Гаффарова: “Көз”.
Р.Зәйдулла: “Кол Гали”

**«ӘДӘБИ УКУ» ДӘРЕСЛЕГЕНӘ**
**МЕТОДИК АҢЛАТМАЛАР**

Искәрмәләр

1. «Аңлатмалы сүзлек», «Фразеологик әйтелмәләр сүзлеге» һәм Этимологик сүзлек һәр дәреслекнең, дәреслек-хрестоматия һәм мөстәкыйльэш дәфтәренең ахырында бирелә. Мөстәкыйль эш дәфтәрендә аңлашылмаган сүзләр астөшермә рәвешендә күрсәтелеп барыла.
2. «Музей йорты»на сәяхәт вакытында укучыларның сөйләм телен, күзәтүчәнлеген, матурлыкка соклана белү хисен, гади генә предметны да образлы итеп күрә белүен үстерергә . музейлар, картинаның язылу тарихы, эшләнеш алымы турында кыскача мәгълүмат бирергә кирәк. Һәр автор белән таныштыру да сорала. Картиналарның кайда саклануын күрсәтү максатыннан, мөстәкыйль эш дәфтәрендә берничә бинаның фотосы урнаштырылды.
3. Мөстәкыйль эш дәфтәре белән эш вакытында укучы сары һәм зәңгәр төстәге карандашлар, гади карандаш белән эш итә *(фломастерлар белән түгел).*
4. Әдәби уку дәресләренең кайберләрендә, «Музей йортына» сәяхәт вакытында, сәнгать әсәрләренең аерым детальләрен яхшылап күзәтү максатында лупа кулланыла.
5. «Музей йорты» белән танышкан вакытта, картиналардан аеруча әһәмиятле фрагментларны кадрлап аерып алу һәм аларны бербөтен итеп карау өчен, билгеле бер размердагы рамкалардан файдаланыла. Әлеге рамкаларны технология дәресләрендә картоннан яисә калын кәгазьдән ясарга мөмкин.Рамкаларның соргылт, яшел, караңгы төстә булуы мөһим (ак төстә түгел). Рамка 6 см x 9 см зурлыкта була һәм һәр яктан 1,5 смполя калдырып эшләнелә.
6. Дәрес өчен материал күп бирелде. Көчле укучылар белән эш оештыру өчен, укытучының барлык мөмкинлекләре дә бар. Һәрбер чыганакта да *(дәреслек, хрестоматия, мөстәкыйль эш дәфтәре)* җитәрлек әсәрләр сайланды.
7. Укытучы өстәмә әсәрләр эзләп мәшәкатьләнмәсә дә була. Күрсәтелгән барлык материалларны эшләп бетерү мәҗбүри түгел, сыйныфның әзерлек дәрәҗәсенә карап, укытучы үзе сайлап ала. Дәрестә бирелгән материал күп дип уйлаганда, мөстәкыйль эш дәфтәрендәге биремнәрне калдырып, материал аз дип уйланган дәресләргә өстәсәң, яисә, өй эше итеп, төрле әзерлектәге укучыларга сайлап бирсәң дә була.
8. Автор әсәрләре ел фасыллары белән туры килмәскә мөмкин. Бу, концепциядә бирелгән кабатлауларга кире кайтып эшләү мөмкинлеге бирү максатында, махсус сайланды.
9. Сәнгать әсәрләренең; берсе булган музыка белән танышу, аны әдәби һәм сынлы сәнгать әсәрләре белән чагыштыру тиеш дип табылды

**УКЫТУ-МЕТОДИК КОМПЛЕКТЫНЫҢ БУРЫЧЛАРЫ:**

«Әдәби уку» укыту-методик комплекты түбәндәге мәсьәләләрне хәл итә.

1. «Перспектив башлангыч мәктәп» комплекты чишәргә тиешле гомумдидактик бурычлар: укучы үзенә кирәкле информацияне «Эчтәлек»;битенә карап таба белергә; исеме буенча текстның эчтәлеген күзалларга; күзәтү эшчәнлеген формалаштырырга *(әдәби һәм сәнгать исәрләреннән аерым детальләрне таба, барлык ваклыклары белән сөйләп бирә)* һәм гомумиләштерергә *(аерым детальләргә нигезләнеп, таралган төрле мәгълүматларны берләштереп, бербөтен картина тудырырга);* «акыллы өлкәннәр» белән хат аша аралашуихтыяҗы формалаштырырга тиеш.

2. Бала яшенә туры килә торган теоретик бурычлар:

а) хайваннар турындагы әкият үзенчәлекләре белән таныштыру: татар халык әкиятләренең, берьяктан, башка халыкларның хайваннар турындагы әкиятләренә охшаш булуы *(төп геройлары — хайваннар, еш кына бер ук төрле мөнәсәбәтләргә керәләр),* икенче яктан, бер-берсеннән аерылуы *(төп геройлар — башка төрле хайваннар, бер-берсе белән мөнәсәбәтләре бөтенләй башка төрле);* хайваннар турыщдагы автор әкиятләренең еш кына халык әкияләренә нигезләнүе *(башлангыч сыйныфларда әле автор нигезләнүе термин буларакәйтелми);* халык әкиятләрендә аерым хайваннарның патшалык итүе *(баш булуы);* хайваннар турындагы әкият героеның һәрвакытта көчсезләрне яклаучы гына түгел, еш кына хәйләкәр, тиктормас, көлкегә калучы икәнлеге турында төшенчә бирү;

3. Әхлакый бурычлар: күзәтүчәнлек, хыяллана белүчәнлек, дуслар белән аралашу, ярата һәм яратыла белү – байлык һәм рухи кыйммәт икәнлеге турында күзаллау булдыру;

4. Эстетик бурычлар: матурлык - ул сине чолгап алган тирәлек, бары тик аны күрә белергә кирәкле турында төшенчә бирү;

5.Сөйләм телен үстерү бурычлары:

Текстта ориентлаша белергә өйрәтү: әсәрләрне өлешләргә бүлү, кирәк урынны табын укып күрсәтү, хис белән белдерелгән өзекнең эчтәлеген ачыклау; әдәби әсәрләргә бәя бирелгәндә һәм сәнгать әсәрләрен караганда предметка - бу «синең» әсәрне аңлау;идеяң икәненҗайлап төшендерү. Дәреслек һәм дәреслек-хрестоматия, мөстәкыйль эш дәфтәре структуралары һәм идея эчтәлекләре буенча бер – берсенә бәйләнеп килә. Мәсәлән, дәреслекнең

« Тылсымлы әкият ка-нуннарын өйрәнәбез: үткәннәрне яңадан китереп, бүгенге тормыш белән бәйлибез», « Фольклорга нигезләнгән хикәяләү. Дастан, риваять һәм легендалар аша тарих белән танышабыз, ә автор әкиятләре хисләр дөньясына чакыра. », « Шагыйрьләр һәмрәс-самнар иҗаты аша та-бигать һәм кешеләрнең матурлыгын аңларга өйрәнәбез», « Безгә кадәр яшәгән яшьтәшләребез тормышы белән танышабыз », “Матурлыкның безгә ничек тәэсир иткәнен аңларга тырышабыз”,

“ Җирдә кеше булу өчен, кеше күпме юллар үтә?” , “Сәнгать дөньясының үзенә генә хас үзенчәлекләрен ачыклыйбыз”, “ Үткәне булмаган халыкның киләчәге юк.Туган ил турында уйланабыз” бүлекләренә дәреслек – хрестоматиянеңһәм эш дәфтәреннең шул ук бүлекләре турыкилә.

4 сыйныф Әдәби уку 34 дәрес (34 атна исәбеннән төзелде)

| № | Дәрес темасы | Дата | |
|---|---|---|---|
| 1 | ***Тылсымлы әкият ка- нуннарын өйрәнәбез: үткәннәрне яңадан ки- череп, бүгенге тормышбелән бәйлибез***<br>Җир йөзендә яшәгәнберенче кешеләрҖир ничек барлыккакилгән?<br>Борынгы легендалар нисөйли? | План | Факт |
| 2 | Тотем агачлар Пәйгамбәрнең тууы. | | |
| 3 | Туган як сылуы – ак каен Абага чәчәге. | | |
| 4 | Абага чәчәге | | |
| 5 | Тотем хайваннар.Татар мифологиясендәАк бүре. Татарстан гербы. | | |
| 6 | Ак бүре (Татар халыкәкияте)<br>Әкиятләрдә ак елан.<br>Еланнар патшасы Шаһ-мара.<br>“Тылсымлы әкият ка- нуннарын өйрәнәбез: үткәннәрне яңадан ки- череп, бүгенге тормыш белән бәйлибез”темасынйомгаклау | | |
| 7 | ***2.Фольклорга нигезлән- гән хикәяләү. Дастан, риваять һәм легендалар аша тарих белән та- нышабыз, ә автор әкиятләре хисләр дөньясына чакыра.***<br>Борынгы шагыйрь КолГали. Кыссаи Йосыф | | |
| 8 | Без – татар балалары. Нәсел агачы. | | |
| 9 | Су асты патшалыгында | | |
| 10 | Айсылу – бәхетле бала. | | |
| 11 | Айсылу – бәхетле бала. | | |
| 12 | ***3. Шагыйрьләр һәм рәссамнар иҗаты аша та бигать һәм кешеләрнеңматурлыгын аңларга өйрәнәбез.***<br>Җирдә миңа ни кирәк? Шәехзадә Бабич шигырь-ләре. | | |
| 13 | Күзге табигатьмизгелләре. Кышкы сандугач.<br>Иртә яме, иртә моңы-җан азыгы. | | |
| 14 | Әнкәм портреты. Иң матур сүз. | | |
| 15 | Кеше ышанмаслык сүзнечын булса да сөйләмә. | | |
| 16 | ***4.Безгә кадәр яшәгән яшьтәшләребез тор- мышы белән таныша- быз.***<br>Газаплы язмыш. Кечкенә хезмәтче. | | |
| 17 | Күз яшьле балачак. | | |
| 18 | Каникуллар- рәхәт вакыт. Балачак хатирәләре | | |
| 19 | ***5.Матурлыкның безгә ничек тәэсир иткәненаңларга тырышабыз.***<br>Көннәрем гөрләп торсын. | | |
| 20 | Каен – урман чибәре. Бөтен дөнья ак кына. | | |
| 21 | Язгы моң. Серле күк. | | |
| 22 | Матурлык дөньясы. Туган як – Иделкөзгесендә. | | |
| 23 | Туган көнгә – салават күпере. Табигать – серле дөнья | | |
| 24 | Аккошлар-сак кошлар. Сандугач – табигать җырчысы. | | |
| 25 | ***6. Җирдә кеше булу өчен, кеше күпме юллар үтә?***<br>Тылсымлы, кодрәтле үлән Кирлемән маҗаралары | | |
| 26 | Урман докторы. | | |
| 27 | Гөмбәләр серен белү кирәк. Бану әби сабагы | | |
| 28 | Аш пешерү хикмәтләре. Татар халык ашлары. | | |
| 29 | Балалар дөньясы. | | |
| 30 | Бүрек-нәни көчек. Бүрек-ышанычлы сакчы. | | |
| 31 | ***7. Сәнгать дөньясының үзенә генә хас үзенчә- лекләрен ачыклыйбыз.***<br>Бәбкә үстерү кыенлыклары. Яз галәмәтләре | | |
| 32 | ***8.Үткәне булмаган ха- лыкның киләчәге юк.Туган ил турында уйлана-быз***<br>Һәркемгә үз Ватаны кадерле. Татарстан флагы | | |
| 33 | Зур тарихлы батыр халкым Авыр елларда. | | |
| 34 | Кыю очучылар. Һәркемгә якын ул туганяк.<br>“Серле ачкыч” мәктәп клубы утырышы. Олимпиада. | | |

Лист согласования к документу № 4уч2023 от 15.09.2023
Инициатор согласования: Бурганова С.И. Директор
Согласование инициировано: 15.09.2023 08:59

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Бурганова С.И. | | Подписано 15.09.2023 - 08:59 | - |